ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

15.07.2020 Казан шәһәре № 55-1/г-2020

Татарстан Республикасы халкына сатыла торган табигый газга ваклап сату бәяләрен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗ номерлы федераль закон, Федераль тарифлар хезмәтенең «Халыкка сатыла торган газга ваклап сату бәяләрен җайга салу буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2011 елның 27 октябрендәге 252-э/2 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның 1 августыннан Татарстан Республикасы халкына сатыла торган табигый газга ваклап сату бәясен 5,89 сум/куб.м күләмендә билгеләргә (өстәмә хакка салым бәясе белән).

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы халкына сатыла торган табигый газга ваклап сату бәяләрен билгеләү турында» 2019 елның 14 июнендәге 4-1/г номерлы карарын 2020 елның 1 августыннан гамәлдән чыккан дип танырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром